**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 15 июнь | № 406

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эш планы турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1007 нче карары белән расланган 2016 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эш планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«III. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын кабул итү кирәк булган мөһим мәсьәләләр» бүлегендә:

«Өстенлекле ИТ-проектларга инвестицияләү өчен «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесенең «чәчү алды» фондын төзү турында» юлын төшереп калдырырга;

«Предприятиеләрнең ИТ-инфраструктурасы мәгълүмат иминлегенә дәүләт катнашыда аудит турында» юлына 3 графада «июнь» сүзен «декабрь» сүзенә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 март, 527-б боерыгы белән расланган 2016 елның II кварталына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эш планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«III. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын кабул итү кирәк булган мөһим мәсьәләләр» бүлегендә:

«Өстенлекле ИТ-проектларга инвестицияләү өчен «Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-парк» технопаркы» дәүләт автоном учреждениесенең «чәчү алды» фондын төзү турында» юлын төшереп калдырырга;

«Предприятиеләрнең ИТ-инфраструктурасы мәгълүмат иминлегенә дәүләт катнашында аудит турында» юлын төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков